КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 3 февраль № 58

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының башкарма хакимият органнары функцияләре кодификаторын раслау турында» 2006 ел, 2 май, 220 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 12 февраль, 38 нче; 2007 ел, 13 июль, 297 нче; 2009 ел, 23 март, 161 нче; 2009 ел, 15 июнь, 386 нчы; 2010 ел, 22 февраль, 92 нче; 2010 ел, 9 апрель, 253 нче; 2011 ел, 6 июнь, 452 нче; 2011 ел, 27 июнь, 515 нче; 2011 ел, 8 сентябрь, 750 нче; 2012 ел, 9 февраль, 93 нче; 2012 ел, 29 март, 250 нче; 2012 ел, 8 июнь, 494 нче; 2012 ел, 19 июнь, 524 нче; 2012 ел, 24 декабрь, 1139 нчы; 2013 ел, 22 февраль, 128 нче; 2013 ел, 11 декабрь, 974 нче; 2014 ел, 23 гыйнвар, 30 нчы; 2014 ел, 7 июнь, 388 нче; 2014 ел, 30 август, 630 нчы; 2014 ел, 12 сентябрь, 659 нчы; 2014 ел, 30 октябрь, 823 нче; 2014 ел, 24 ноябрь, 902 нче; 2014 ел, 3 декабрь, 940 нчы; 2015 ел, 2 февраль, 49 нчы; 2016 ел, 15 апрель, 227 нче; 2016 ел, 20 август, 578 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының башкарма хакимият органнары функцияләре кодификаторына түбәндәге үзгәрешләре кертергә:

03.03.01 коды белән функция исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Төбәк һәм муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген гамәлгә ашыруны тәэмин итү»;

03.03.02 коды белән функция исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципальара һәм шәһәр яны элемтәсендә һәм шәһәр яны элемтәсендә тимер юл транспорты белән халыкка һава, су, автомобиль транспорты белән, җиңел таксины да кертеп, транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру (рөхсәт бирү һәм аны яңадан рәсмиләштерү, рөхсәтнең дубликатын бирү, рөхсәтнең гамәлен вакытыннан алда туктату, бирелгән рөхсәтләр реестрын алып бару өлешендә), җиңел таксида пассажирлар һәм багаж йөртү өлкәсендә төбәк дәүләт контролен гамәлгә ашыру»;

Кодификаторның «Өченче» графасына түбәндәге эчтәлекле юллар өстәргә:

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | «03.03.04 | Төбәк һәм муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларының саклануын тәэмин итүгә төбәк дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру | | |
| | | | | 03.03.05 | Автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге белән идарә итүне оештыру». | | |

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 317 карары белән расланган (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 29 декабрь, 660 нчы; 2006 ел, 19 июнь, 312 нче; 2010 ел, 31 май, 419 нчы; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 26 октябрь, 890 нчы; 2011 ел, 23 декабрь, 1060 нчы; 2012 ел, 2 июнь, 466 нчы; 2012 ел, 10 октябрь, 846 нчы; 2013 ел, 19 март, 185 нче; 2013 ел, 4 декабрь, 955 нче; 2013 ел, 11 декабрь, 974 нче; 2014 ел, 4 июнь, 376 нчы; 2016 ел, 19 март, 150 нче; 2016 ел, 29 октябрь, 796 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) Татарстан Республикасының Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Министрлык түбәндәге төп функцияләрне гамәлгә ашыру өчен җавап тота:

билгеләнгән тәртиптә транспорт комплексы белән идарә итү (03.03);

төбәк яки муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген гамәлгә ашыруны тәэмин итү (03.03.01);

муниципальара һәм шәһәр яны элемтәсендә һәм шәһәр яны элемтәсендә тимер юл транспорты белән халыкка һава, су, автомобиль транспорты белән, җиңел таксины да кертеп, транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру (рөхсәт бирү һәм аны яңадан рәсмиләштерү, рөхсәтнең дубликатын бирү, рөхсәтнең гамәлен вакытыннан алда туктату, бирелгән рөхсәтләр реестрын алып бару өлешендә), җиңел таксида пассажирлар һәм багаж йөртү өлкәсендә төбәк дәүләт контролен гамәлгә ашыру (03.03.02);

төбәк һәм муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларының саклануын тәэмин итүгә төбәк дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру (03.03.04);

автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге белән идарә итүне оештыру (03.03.05).»;

3.3 пунктта:

егерме тугызынчы, илле дүртенче, илле җиденче – алтмышынчы абзацлар үз көчен югалткан дип танырга;

алтмыш сигезенче абзацка «, шулай ук юл хуҗалыгы өлкәсендә муниципаль программалар» дигән сүзләр өстәргә;

җитмеш өченче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«законнар нигезендә төбәк яки муниципальара әһәмияттәге гомуми кулланылыштагы автомобиль юлларын төзүне, төзекләндерүне, капиталь ремонт ясауны оештыра;

транспорт чараларының өзлексез һәм имин хәрәкәтенә ярдәм итү максатларында техник регламентлар таләпләре нигезендә төбәк яки муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлау һәм карап тоту үткәрүне оештыра;

транспорт-эксплуатацияләү сыйфатларының техник регламентлар таләпләренә туры килүне билгеләү максатларында төбәк яки муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларының техник хәлен бәяләү үткәрүне оештыра;

төбәк яки муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлау һәм карап тоту буенча эшләр оештыру һәм үткәрү буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыручы юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр техник регламентлар таләпләрен үтәүне контрольдә тотуны гамәлгә ашыра;

ике яки күбрәк муниципаль берәмлек (муниципаль районнар, шәһәр округлары) территориясендә автомобиль юлларын төзү, төзекләндерү яки капиталь ремонт планлаштырылган очракта төбәк яки муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларын, шулай ук шәхси автомобиль юлларын төзү, төзекләндерү һәм капиталь ремонт ясау өчен рөхсәт бирә;

автомобиль юлларын төзү, төзекләндерү яки капиталь ремонт ике яки күбрәк муниципаль берәмлек (муниципаль районнар, шәһәр округлары) территориясендә гамәлгә ашырылган очракта төбәк яки муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларын, шулай ук шәхси автомобиль юлларын кулланылышка кертүгә рөхсәтләр бирә,

ел саен юлларның һәлакәт куркынычы булган участоклары исемлеген раслый һәм юл-транспорт һәлакәтенә китергән сәбәпләрне һәм шартларны бетерүгә юнәлдерелгән чараларны эшли;

Татарстан Республикасы территориясендә җиңел таксида пассажирлар һәм багаж йөртү буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыруга рөхсәтнең гамәлдә булуын вакытыннан алда туктата.»;

5.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«министр урынбасарлары, структур бүлекчәләр җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре эшчәнлеге нәтиҗәлелегенең төп күрсәткечләре исемлеген раслый;

үзенә беркетелгән дәүләт идарәсе функцияләрен тормышка ашыру буенча процесслар һәм и процедураларны үтәү стандартларын раслый һәм аларны үтәүне тәэмин итә;

эшчәнлек нәтиҗәлелегенең төп күрсәткечләренә ирешүгә бәйле рәвештә стимуллаштыручы түләүләр күләмен исәпләү тәртибен билгеләү турында нигезләмәне раслый;

Министрлык өчен һәм хезмәт законнарында билгеләнгән эшчәнлек нәтиҗәлелегенең төп күрсәткечләре нигезендә үз ведомствосындагы учреждениеләр җитәкчеләре белән хезмәт шартнамәләре (контрактлары) төзи.»;

түбәндәге эчтәлекле $5.1^1$ пункт өстәргә:

«5.1[1]. Министрлыкның структур бүлекчәләре һәм хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү министр боерыгы белән расланган нәтиҗәлелекнең төп күрсәткечләре исемлеге нигезендә гамәлгә ашырыла.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2017\58.docx